**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2015 ел, 3 июль

№ 483

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» 2005 ел, 22 гыйнвар, 20 нче карары белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» 2005 ел, 22 гыйнвар, 20 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 30 май, 245 нче; 2005 ел, 17 ноябрь, 539 нчы; 2006 ел, 16 ноябрь, 547 нче; 2007 ел, 5 февраль, 33 нче; 2007 ел, 28 март, 113 нче; 2007 ел, 13 июль, 295 нче; 2008 ел, 31 гыйнвар, 48 нче; 2008 ел, 12 март, 157 нче; 2008 ел, 29 май, 344 нче; 2009 ел, 4 февраль, 64 нче; 2009 ел, 21 сентябрь, 654 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2013 ел, 21 октябрь, 781 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – ТР ХХЭТһСЯМ);»;

текстка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – ТР МһФМ);

халыкка чыбыклы телефон элемтәсе хезмәтләрен күрсәтүче оешмалар (алга таба – элемтә операторлары) (килешү буенча).»;

унөченче абзацны төшереп калдырырга;

текст буенча:

«ТР СЯМ» сүзләрен «ТР ХХЭThСЯМ» сүзләренә алмаштырырга;

тиешле килешләрдәге «филиаллары» сүзен тиешле килешләрдәге «бүлекләре» сүзенә алмаштырырга;

тиешле килешләрдәге «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» сүзләрен тиешле килешләрдәге «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

4 нче пункт үз көчен югалткан дип танырга;

6 нчы пунктның таблицасында:

5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «5. | ЗАГС | Хисап чоры дәвамында туучылар, үлүчеләр турында мәгълүмат тапшыру | электрон | атна саен (дүшәмбе), шулай ук һәр айның 1 сендә | ТР ХХЭThСЯМ»; |

9 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «9. | ТР буенча РПФБ | Түбәндәгеләрне тапшырырга:<br>хезмәткә яраксыз гражданнарны карауны гамәлгә ашыручы затларга пенсияләр, өстәмә айлык матди тәэминат, компенсация түләүләре күчерү турында мәгълүмат; | электрон | агымдагы айның 15 енә кадәр | ТР ХХЭThСЯМ»; |
| | | Советлар Союзы Геройлары, Россия Федерациясе Геройлары, Дан ордены тулы кавалерлары һәм аларның гаилә әгъзалары федераль мәгълүматлар базасының төбәк сегменты белешмәләре | | хисап аеннан соң килүче айның 10 сына кадәр | |
| | | физик затларның Татарстан Республикасы территориясеннән читтә вафат булу фактларын теркәү турында белешмәләр; | | хисап аеннан соң килүче айның 5 сенә кадәр | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Социаль хезмәтләр җыелмасы рәвешендә социаль дәүләт ярдәме алуга хокуклы затларның федераль регистрының төбәк сегменты белешмәләре | | хисап аеннан соң килүче айның 10 сына кадәр һәм агымдагы айның 20 сенә кадәр | |

14 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «14. | ТР ХХЭТһСЯМ | гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү чаралары түләүгә республика заявкасы | электрон, документлар | түләү аеның 8 енә кадәр | ТР ФМ, ТР ФМ Казначылык департаменты»; |

23 нче пунктны төшереп калдырырга;
таблицага түбәндәге эчтәлекле 26 – 28 пунктлар өстәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «26. | ТР МһФМ | «Татарстан Республикасында электрон мәгариф» мәгълүмати системасыннан ведомствоара соратып алу юлы белән баланың Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмасында укуы турында белешмәләр алу | электрон | хисап аеннан соң килүче айның 3 сенә кадәр | ТР ХХЭТһСЯМ |
| 27. | ТР ХХЭһ СЯМ | Хисап аенда телефон өчен абонент түләве буенча чыгымнарны каплауга субсидияләр алучы гражданнар яшәгән йорт хуҗалыкларының республика реестры | электрон | хисап аеның 25 енә кадәр | элемтә операторлары |
| 28. | Элемтә операторлары | Хисап аенда телефон өчен абонент түләве буенча чыгымнарны каплауга субсидияләр алучы гражданнар яшәгән йорт | электрон | хисап аеннан соң килүче айның 3 сенә кадәр | ТР ХХЭТһСЯМ ». |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | хуҗалыкларында чыбыклы телефон элемтәсе булу-булмау турында мәгълүмат | | | |

2. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

2015 елның 1 сентябренә кадәр, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының муниципаль районнардагы (шәһәр округларындагы) социаль яклау идарәләре (бүлекләре) (алга таба – территорриаль социаль яклау органнары) халыкка чыбыклы телефон элемтәсе хезмәтләрен күрсәтүче оешмалар (алга таба – элемтә операторлары) белән мәгълүмат алмашу өчен, «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмати системасын эшләп бетерүне;

территорриаль социаль яклау органнарын, элемтә операторлары белән мәгълүмат алмашу өчен, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән килешү буенча компьютер җиһазлары һәм оештыру техникасы белән;

элемтә операторлары тарафыннан территорриаль социаль яклау органнарына телефон өчен абонент түләве буенча чыгымнарны каплауга субсидияләр (алга таба – субсидия) алучыларның йорт хуҗалыкларында чыбыклы телефон элемтәсе булу-булмау турында даими рәвештә актуаль мәгълүмат тапшыруны.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

2015 елның 1 сентябреннән субсидияләр алучыларның йорт хуҗалыкларында чыбыклы телефон элемтәсе булу-булмау турында актуаль мәгълүмат тапшыру буенча элемтә операторлары белән мәгълүмат алмашуны оештыру;

2015 елның 1 октябреннән 20 октябренә кадәр, элемтә операторлары мәгълүматлары буенча чыбыклы телефон элемтәсе булмаган гражданнарга 2015 елның 1 ноябреннән субсидия түләү туктатылу тәртибе турында гражданнарга мәгълүмат бирүне оешытру.

4. Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнарына 2015 елның сентябрь аена торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә счетларда субсидия түләүне туктату тәртибе турында мәгълүмат урнаштыруны тәкъдим итәргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков